Бүгенге санда




"Доктор Дуслык" проекты беренче чыгарылышын тәкъдим итә. *3 бит*


# Дуслык
Дружба

Нурлат шәһәре һәм Нурлат районы газетасы

1931 елның 9 июленнән бирле чыга

Җомга 13 ноябрь 2015 ел

№83 (10612)


**14 ноябрьгә һава торышы:** болытлы һава, кар, алмашынучан юнәлешле җил, 2 м/с; температура көндез -1°С, төнлә -3°С

Телефоннар: 2-36-13, 2-36-20.

ХӘБӘРЛӘРЕГЕЗНЕ КӨТӘБЕЗ

### ҖИРЛЕ СОВЕТ УТЫРЫШ ҮТКӘРДЕ

Шул көннәрдә "Бердәм Россия" Бөтенроссия сәяси партиясенең Нурлат муниципаль районы Советындагы депутат берләшмәләре җитәкчеләренең җирле Советы беренче утырышын үткәрде. Утырышта оештыру мәсьәләләре каралды, президиум һәм җитәкче орган сайланды. Җирле Советны Андреевка башлангыч бүлекчәсе секретаре Надежда Егорова җитәкләячәк.

### ЯШЬЛӘР КОНФЕРЕНЦИЯСЕ ҮТТЕ

Кичә "Нурлатнефть" НГДУсы базасында яшьләрнең хисап-сайлау конференциясе үтте. Аның эшендә "Татнефть" ПАОның яшьләр комитеты вәкиле Айдар Шәрифуллин катнашты.

### ӨЛКӘН СЫЙНЫФ УКУЧЫЛАРЫ БЕРЛӘШТЕ

Яңа уку елы башыннан районның өлкән сыйныф укучылары советы эшли башлады. Бүген анда 34 әгъза исәпләнә. Советның беренче утырышы бу атнада шәһәрнең 4нче мәктәбендә узды. Өлкән сыйныфлар Советының рәисе итеп 4нче мәктәпнең 11 сыйныф укучысы Александр Петрен сайланды. Утырыш фикер алышулар белән дәвам итте.

### СЫЙНЫФ ҖИТӘКЧЕЛӘРЕ УКЫЙ

"Ышаныч" психолого-педагогик, медик-социаль үзәге базасында район мәктәпләренең сыйныф җитәкчеләре өчен "Синң кагыла торган бар нәрсә" программасы буенча семинар-практикумнар оештырылган. Хәзерге вакытта 30 педагог уку үтә. Эш барышында алар белән стресска каршы торучанлык, конфликтлы хәлләрдән чыгу һәм башка сораулар карала. Шундый ике очрашу узган инде, киләселәре 17 ноябрь һәм 2 декабрьгә планлаштырылган.

# "Татарстанның алтын дагасы" Нурлат белән танышты




Республика туроператорлары Мәдәният сарае фойесында күргәзмә белән танышты

**"Татарстанның алтын дагасы" туристик маршрутлар челтәре буенча мәгълүмати – реклама туры үз маршрутын чәршәмбе көнне Нурлат районыннан башлап җибәрде.**

Туризм буенча Татарстан Республикасы Дәүләт комитеты һәм Әлмәт шәһәренең "Интурмед" җәмгыяте оештырган тур республиканың көньяк – көнчыгыш районнарында булып, туризмның яңа юнәлешләрен үстерүне максат итә.

- Республикадагы әлеге турны "Россиянең алтын боҗрасы" туристлык маршрутына аналог итеп эшләмәкче булабыз, - ди "Интурмед" җәмгыяте генераль директоры Азат Низамов. – "Россиянең алтын боҗрасы" туры - ул Мәскәү янындагы тарихи урыннарга автобуста бер атналык сәяхәт. Шундый маршрутны Татарстанда да булдыру идеясе туды. Республиканың көньяк–көнчыгыш районнарында тарихи – уникаль урыннар бихисап. Без көньяк – көнчыгыш зонаның 16 районында булып чыктык. Бу зона – Татарстанның ерак районнары.

*(Ахыры 2нче биттә)*

АКТУАЛЬ

# Укытучыларның һөнәри әзерлеген тикшерделәр

**Районның 313 педагогы көзге каникуллар чорында беренче тапкыр диагностик тестлаштыру узды.**

Чыгарылышларны БДИга әзерләүче педагоглар 5 ноябрь көнне рус, татар, инглиз һәм немец телләре, тарих, җәмгыять белеме, математика, информатика, физика, химия, география һәм биология буенча тест биремнәрен үтәделәр. Район укытучылары әйтүенчә, имтиханнар укытучыларга яхшы таныш булган, чөнки категория алу өчен дә шундый тестлар үтәләр икән. Педагогларның диагностик тестлаштырулары үткәрү формасы һәм биремнәр буенча да укучыларның БДИсына охшаган. Укытучылар өчен дә КИМнар эшләнгән, 3 сәгать вакыт бирелгән. Район мәгариф бүлегендә әйтүләренчә, имтиханнарның контроль кәгазьләре республика мониторинг үзәгенә җибәрелгән. Педагогларның тестлары да укучыларныкы кебек үк баллар белән бәяләнәчәк.

Мәктәп педагогларының тест нәтиҗәләре якын көннәрдә билгеле булачак. ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы белгечләре әйтүенчә, тестларда тиешле баллар җыя алмаган укытучыларга бернинди административ чаралар да күрелмәячәк икән. Начар билге алучы укытучыларга квалификация күтәрү курсларын үтәргә тәкъдим итәчәкләр.

**Зилия ӘКСАНОВА**


# Призларыбыз сезне көтә!

**9 ноябрьдән 19ына кадәр игълан ителгән призлы декадабыз дәвам итә. Шул көннәрдә киләсе яртыеллыкка район газетасына язылсагыз, сез дистәдән артыграк призыбызның, бәлки стена сәгате һәм үтүкнең хуҗасы булып куярсыз.**



**Газетага редакциядә һәм почта бүлекчәләрендә язылырга мөмкин.**


**Газетаның электрон версиясен nurlat-tat.ru сайтында укыгыз**

# “Доктор “Дуслык” дәвага алына



Мансур Разыйх улы Галимов,
Нурлат район үзәк хастаханәсе баш табибы урынбасары
Татарстан Республикасының атказанган табибы, сәламәтлек саклау отличнигы. Югары квалификацион категорияле табиб:

БҮГЕН БЕЗ ГАЗЕТАНЫҢ РАЙОН ҮЗӘК ХАСТАХАНӘСЕ ЯРДӘМЕНДӘ ОЕШТЫРГАН ШУЛ ИСЕМДӘГЕ ПРОЕКТЫН БАШЛАП ҖИБӘРӘБЕЗ




## СӘЛАМӘТЛЕККӘ – ХӘЕРЛЕ ЮЛ!

**–Сәламәт ана, исән-сау бала–болар бер-берсенә нык бәйләнгән төшенчәләр. Илнең иминлеге гаиләләр иминлегеннән башлана. Һәм газета редакциясенең аналар һәм балалар сәламәтлегенә юнәлтелгән проект тәкъдим итүе–бик актуаль һәм кирәкле гамәл. Булачак әниләргә мәгълүмат ташкынынннан иң кирәклеләрен генә сайлап алу мөмкинлеге булдыру, үзенең һәм туачак сабыеның сәламәтлегенә дөрес караш тәрбияләүдә булышу бик мөһим бит. Без үз чиратыбызда проект барышында квалификацияле табиблар консультациясе биреп барырга ышандырабыз һәм проектның уңай нәтиҗә бирәсенә өметләнәбез.**

# Могҗиза көткәндә

**Сез әни булачагыгызны белдегезме? Йөклелек чоры әйбәт узсын өчен, үз-үзеңне ничек тотарга? Кайчан исәпкә басарга? Җитди чор–йөклелекне планлаштырудан алып бала тудыру йортына кадәрге араны без поликлиниканың гинекологоия бүлеге мөдире – акушер-гинеколог Әминә Мингалимова белән үтәчәкбез.**

Аңлавыбызча, гаилә ЗАГСтан түгел, ә гаиләне планлаштыру кабинетыннан башлана.

*– Бу иң элек, бу яшьләр вакытсыз йөклелектән, җенси юл белән күчә торган инфекцияләрдән саклану профилактикасы турында мәгълүмат алсын өчен эшләнә. Биредә үк алар йөклелеккә преконцепцион әзерлек буенча да киңәшләр алалар. Әйтик, йөклелек әйбәт узсын өчен, хатын-кыз алдан ук витаминнар кабул итәргә, тикшеренүләр узарга кирәклеген белергә тиеш. Ә сәламәт йөклелек өчен аның гаиләдә көтеп алынган булуы шарт.* Хатын-кызлар консультациясендә 12 атнага кадәр исәпкә басу – иң мөһим пунктларның берсе.

*– Булачак ана йөклелеген белүгә, хатын-кызлар консультациясенә исәпкә басарга тиеш. Йөкле хатын-кыз 12-14 атна эчендә РКБның перинаталь үзәгендә түләүсез ХТЧ һәм РАРР-тестка кан анализы, яралгының сау-сәламәтлеген тикшерүгә скрининг УЗИ тикшеренүләре узарга тиеш. Һәм бу тикшеренүне бездә йөкләрнең 85 проценттан артыгрвгы уза. Кызганычка каршы, исәпкә соң басучылар, читтән килүчеләр яки дини инанулар буенча кайбер хатын-кызлар аны узмыйча калалар. Кайберәүләргә барып кайту да финанс кыенлыгы тудыра.*

*Исәпкә басып, хатын-кызлар квалификацияле табиблык ярдәме ала башлыйлар. Ихтыяҗ булганда, аларны электрон чират буенча РКБның арадаш белгечләренә консультациягә җибәрәбез. Без йөклелекне өч риск төркеменә бүлеп карыйбыз. Урта һәм югары йөклелек төркеменә караган хатын-кызларны 32нче атнада һичшиксез РКБга перинаталь консилиумга юллыйбыз, анда РКБның табиблар комиссиясе кайда бала табарга икәнлеген хәл итәләр. Маршрутлаштыру буенча приказ нигезендә, бездә 3 дәрәҗәдә бала таптыру билгеләнгән. Беренчесе – безнең район үзәк хастаханәсе, икенчесе – Чистай перинаталь үзәге, өченче дәрәҗә исә югары риск төркеменә караган йөклеләргә кагыла.*

Исәптә торучы барлык йөкле хатын-кызлар бушлай корсак куышлыгындагы инфекцияләргә тикшеренү үтәләр, кирәкле медицина препаратлары белән тәэмин ителәләр.

*– Күзәтү барышында йөклеләргә 30 атнадан һәм соңрак тудыру сертификатлары тапшырыла. Сертификат акчаларына тимер-йодлы препаратлар, витаминнар комплексы, карау өчен бер тапкыр кулланыла торган стериль гинекологик җыелмалар алына. Йөклелек чорында аларга поликлиникада һәм тудыру йортында өч тапкыр УЗИ, гаиләне планлаштыру кабинетында йөклеләрне бала табуга психопрофилактик әзерләү үткәрелә. 36 атнадан соң йөклеләр физиотерапия бүлегенә дәвалау физкультурасына йөриләр.Йөклеләр өчен бассейн бик файдалы, йөзгәндә умыртка баганасыннан нагрузка төшә, арыганлык бетә. Бу бала туганнан соң тромботик катлауланауларны да булдырмаска ярдәм итә. Табиблар рекомендацияләре буенча, дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләре шифаханәләргә түләүсез юлламалар алырга хокуклылар.*

Йөклелек барышында иң мөһим моментларның берсе, әлбәттә инде, тукланy. Уңайлы кием кияргә кирәклеге турында да онытмагыз.

*– Йөклеләр ризыкның күләменә түгел, сыйфатына игътибар бирергә тиешләр. Бала табасы вакытка авырлык 10, иң күбе 12 кг.нан артмаска тиеш. Менюдан татлы һәм камыр ризыкларын алырга, ә ачытылган сөт продуктларын, эремчек, диңгез балыгы, майсыз ит, яшелчә, тәмләткечләрне арттырырга киңәш итәбез. Дөрес киенү турында да уйланырга кирәк. Иркен кием, ә 20 атнадан соң бала туганга кадәрге бандаж киярге киңәш итәбез, бу вакытыннан алда бала табуны профилактикалау һәм умыртка сөягенә нагрузканы киметү ягыннан мөһим.*

*Йөклеләр хатын-кызлар консультациясендә күзәтелгән чорда барлык медперсонал булачак әнигә бар күңел җылыларын бирергә тырышалар. Безнең өчен йөклелекнең катлауланауларсыз узуы бик мөһим, бу бала сәламәт тусын өчен кирәк. Урамнан барганда, үзебездә исәптә торган һәм сау-сәламәт бала тапкан хатын-кыз белән очрашу безнең өчен иң рәхәт мизгел. Без көчебез, энергиябез һәм вакытыбызны кызганмыйча шуның өчен хезмәт куябыз да.*

Сирень СӘМӘРХАНОВА



Әминә Хафизовна Мингалимова, Куйбышев медицина институтын тәмамлаган, 1988 елның 8 августыннан Нурлат район үзәк хастаханәсендә эшли, югары категорияле табиб.

**Быел хатын-кызлар консультациясенә 17–44 яшьләрдәге 578 йөкле хатын-кыз исәпкә баскан. Төп контингентны 25–33 яшьтәге йөклеләр тәшкил итә.**

**В КОНСУЛЬТАТИВНО-ДИАГНОСТИЧЕСКОМ ЦЕНТРЕ «САУЛЫК», Г. НУРЛАТ, УЛ. ЖЕМЧУЖНАЯ, 25, ВЕДУТ ПРИЕМ СПЕЦИАЛИСТЫ:**

*Подростковый гинеколог.
*Гинеколог – репродуктолог.
*Онколог – эндокринолог.

Для сохранения вашего здоровья мы оказываем услуги:
- Помощь при инфекционно-воспалительных заболеваниях, передающихся половым путем.
- Обследование и помощь при нарушении менструального цикла.
- Диагностика заболеваний шейки матки.
- Решение проблем репродуктологии.
- Кольпоскопическое исследование.
- Помощь при эрозии, других доброкачественных заболеваниях шейки матки методом радиоволновой хирургии.
- Обследование, подготовка и ведение беременности.
- Решение проблем гинекологической эндокринологии.
- Эхосальпингоскопия – щадящая процедура проверки маточных труб на высокотехнологичном оборудовании.
- Фолликулометрия – исследование на высокотехнологичном оборудовании, позволяющее определить овуляцию и выбрать благоприятные дни планирования беременности.
- Исследование плода на высокотехнологичном оборудовании и скрининг 1, 2 и 3 триместра для выявления УЗ-маркеров хромосомных аномалий.
- Доплерометрия (УЗДГ), контроль и оценка маточно-плацентарного кровотока.

**Внимание!**
**Чтобы вовремя выявить такие заболевания, нужно регулярно посещать гинеколога.**
**Подробную информацию вы можете получить на сайте: www.saulek.ru**

**Справки и предварительная запись по т.: 2-43-03, 8-927-037-40-01.**

ООО «Услуга» КДЦ «Саулык». Лиц. ЛО-16-01-001191 от 30.09.2010г. ОГРН 1021605358103.

**Имеются противопоказания. Необходима консультация специалиста**

Реклама

**ОДЕЖДА ДЛЯ БУДУЩИХ МАМ.**
**Универсальный рынок. 3 ряд. 44 место.**
Реклама

Медицинский центр «ВАШ ДОКТОР»
- Врачи проведут исследования на высокотехнологичном оборудовании, диагностика беременности на ранних сроках, в I,II,III триместрах
- Кольпоскопия. Вопросы репродуктологии.
- Помощь при воспалительных заболеваниях органов малого таза
- Помощь при заболеваниях шейки матки аппаратным радиоволновым методом

Нурлат ул. Салимжанова 13
на кольце около продуктового рынка
Запись по телефонам
2-22-22, 8-927-248-97-79

ООО «Актив» Лиц. ЛО 16-01-004077 от 27.04.2015 г. ОГРН 1131677001114
ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ. НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТА.
Реклама

САМЫЙ ЗАМЕЧАТЕЛЬНЫЙ ОТДЫХ ДЛЯ БЕРЕМЕННОЙ – СМЕНА ОБСТАНОВКИ, ОТСУТСТВИЕ ВНЕШНИХ РАЗДРАЖИТЕЛЕЙ. ДЛЯ ЭТИХ ЦЕЛЕЙ ОТДЫХ ДЛЯ БЕРЕМЕННЫХ В **ООО «САНАТОРИЙ – ПРОФИЛАКТОРИЙ «ЛУЧЕЗАРНЫЙ»** ПРИОБРЕТАЕТ ОСОБУЮ АКТУАЛЬНОСТЬ.

Оздоровление беременной женщины в санатории «Лучезарный», в отличие от поездок в более удаленные места отдыха, выгоден не только экономически, но и отсутствием акклиматизации беременной. Поэтому, для отдыха беременных мы рекомендуем выбрать наш комплекс оздоровительных процедур.
- **бассейн 1 посещение – 110 руб.**
- **ингаляция 1 процедура – 101руб.**
- **зал ЛФК 1 сеанс – 143 руб.**
- **вакуумный массаж 1 процедура – 117 руб.**
- **кислородные коктейли (240 мл) - 53 руб.**
- **циркулярный душ 1 процедура – 128 руб.**

Беременным 15% скидка на указанные услуги*

Санаторий «Лучезарный» работает без выходных.

Те же самые процедуры могут принять и другие жители города и района, чтобы с пользой провести выходные и праздничные дни.

**Наш адрес:**
**423040, Республика Татарстан, г.Нурлат, ул. Хамадеева Р.С., д.2а**
**Тел: 8(84345) 2-36-63**
**Регистратура: 8(84345) 2-22-57**

*Сайт в Интернете:www.nursan.su*
**Скидка предоставляется с 13 ноября по 31 декабря 2015г. Подробности на сайте и по телефонам.*

**Организатор ООО «Санаторий - профилакторий «Лучезарный»**
**Лиц. ЛО-16-01-004174 от 25.05.2015 г. ОГРН 1051648004924**

**Имеются противопоказания. Необходима консультация специалиста**

Реклама

# ВӘЗГЫЯТЬ

БЕЗНЕҢ ӘҢГӘМӘ

## Җир – хуҗалы, хуҗа тәртипле булсын




**Агымдагы елның 1 мартыннан Нурлат муниципаль районының Җир һәм милек мөнәсәбәтләре палатасы Россия Федерациясе Җир кодексына кертелгән яңа үзгәрешләр буенча эшли. Палата рәисе Рәмис Шәйхетдинов белән әңгәмәбез яңа үзгәрешләр һәм районлагы җир мәсьәләләренә кагылышлы вәзгыять хакында.**

**- Рәмис Хәмзинович, белүемчә, үзгәрешләр нигездә җир мөнәсәбәтләренә, җир участоклары белән эш итү тәртибенә кагыла...**

– 171нче Федераль закон нигезендә, 1 марттан Россия Федерациясе Җир кодексына үзгәрешләр, өстәмәләр кертелде. Бу җәмәгать милегендә булган җир участокларын бирүнең гамәлдәге тәртибен административ каршылыклар һәм кирәгеннән артык булган килешүләрне азайту юлы белән камилләштерү максатыннан кертелде. Мәсәлән, элегрәк җир участоклары бары муниципаль район карамагында булып, аларга бәйле карарларны район башкарма комитеты гына кабул итә алган булса, хәзер алар җирле үзидарә органнарына – авыл җирлекләренә һәм шәһәр башкарма комитетларына күчте. Индивидуаль торак төзелешенә һәм сәнәгать максатларына җир участоклары бирү шартлары да үзгәрде. Әлбәттә, яңалыклар кертү яңа белемнәр таләп итә, әмма без алда торган мәсьәләләрне хәл итә барабыз.

**– Бүгенге көндә җир һәм милек мөнәсәбәтләре палатасына халык нинди сораулар белән аеруча еш мөрәҗәгать итә?**

– Пай җирләрен бүлгәндә нинди дер сәбәпләр аркасында өлешсез калучылар, мирасчылар еш килә. Пайчылар исемлеге һәм шәһадәтнамәләрен югалтып, я булмаса пайлар өчен түләүдән канәгать булмыйча килүчеләр дә бар. Бу сораулар халык җыеннарында, очрашуларда да иң еш күтәрелә торганнардан. Әмма бу очракта башкарма хакимиятнең бары консультатив ярдәм күрсәтү хокукы гына булуын искәртү кирәк. Пай мәсьәләләре җир милекчеләре белән арендаторлар арасында үзара, я булмаса суд аша хәл ителә. Ә пай өчен түләү мәсьәләсенә килгәндә, аның күләме һәм формасы да арендатор белән җир хуҗалары арасындагы килешү нигезендә билгеләнә, бу очракта авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы бары түләүнең күләменә кагылышлы рекомендация генә бирә.

**– Авыл хуҗалыгы багланышындагы җирләрдән рациональ файдаланмау, хуҗасыз авыл хуҗалыгы объектлары мәсьәләләре дә бар бит әле.**

– Әйе, бу мәсьәләләр район башлыгы Равил Кузюровның да, авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенең дә җитди контролендә бүгенге көндә. Авыл хуҗалыгы багланышындагы җирләрдән рациональ файдаланмау асылда вак фермерлык хуҗалыкларына, шәхси ярдәмче хуҗалыкларга хас. Матди базаларының начар булуы аркасында алар үз җир участокларын тиешле дәрәҗәдә эшкәртә һәм, нәтиҗәдә, аннан мул уңыш та ала алмыйлар. Һәм, әлбәттә инде, тиешенчә эшкәртелмәгән җирнең табигый уңдырышлылыгы да кими бара. Җирдән файдаланганда законнарны истә тотмаучылар һәм аннан максатчан файдаланмаучыларга закон нигезендә административ җаваплылык каралган.

Авыл хуҗалыгы багланышындагы хуҗасыз объектлар – ташландык фермалар, остаханәләр һәм башка корылмалар буенча да эшлисе бар әле. Элеккеге авыл хуҗалыгы предприятиеләреннән калган мондый "мираслар" һәр җирлектә диярлек бар, һәм алар бер яктан авылларның ямен алып торсалар, икенче яктан иминлек буенча да куркыныч тудыра. Сүтеп алу яисә яңа хуҗаларга бирү өчен аларны хуҗасыз итеп тану кирәк. Бу эшне җирле үзидарә органнары җир һәм милек мөнәсәбәтләре палатасы белән берлектә алып бара һәм хуҗасыз объектлар билгеле бер процедура́р үтелгәннән соң авыл җирлекләре балансына күчә. Бу юнәлештә эшне оештыру максатыннан район башкарма комитеты карары нигезендә, комиссия дә төзелде һәм ул бу мәсьәләләрне контрольдә тотачак.

Авылларда исә су белән тәэмин итү объектларын, каты көнкүреш калдыклары полигоннарын, үләт базларын һәм зиратларны кадастр исәбенә кую һәм теркәү эшен дәвам иттерү дә көн кадагындагы мәсьәлә. Шул ук вакытта авыл җирлекләрендә электрон хуҗалык китапларын тутыруны төгәлләү дә зур бурыч итеп куела. Авыл җирлекләрендәге барлык мәгълүматларның электрон версиягә күчерелүе безгә онлайн режимда җирлек буенча да, аерым гражданнар буенча да мәгълүматларны алырга мөмкинлек бирер һәм процедураларны гадиләштерер иде.

**- Соңгы елларда шәһәрдә яңа микрорайоннар барлыкка килде, аларда индивидуаль торак төзелеше зур куәт белән бара. Бу сезгә дә өстәмә эш күләме йөкли торгандыр.**

- Әйе. Без шәһәр башкарма комитеты белән берлектә яңа микрорайоннарда индивидуаль торак төзелеше өчен бүлеп бирелгән җирләргә ревизияләр үткәрәбез. Кызганычка каршы, ревизияләр микрорайоннарда төзелеш алып барылмаучы участокларның шактый булуын күрсәтә. Закон нигезендә, участок сатылганда анда өч ел эчендә объект төзелергә тиеш дигән шарт куела. Әмма күп кенә участокларны, күрәсең, алга таба сату максаты белән алганнар, һәм алар рәсмиләштерелмәгән килеш буш тора. Аларның хокукый хуҗаларын ачыклау буенча тиешле процедуралар үткәрелгәннән соң, җир участокларын сайлау һәм бүлеп бирү буенча ведомствоара комиссия карары буенча андый җирләр сатуга куела. Бүгенге көндә 28 участок аукционга әзерләнде инде, эш алга таба да дәвам иттереләчәк.

**- Еш кына шәһәр йөзен тиешсез урында һәм эстетик яктан зәвыксыз итеп төзелгән гаражлар да бозып тора. Аннан, шәһәргә керү юлында инде ташландыкка әверелеп бара торган дача кишәрлекләре дә юк түгел.**

- Совет чорында күпфатирлы йортлар тирәсендә халык үз гаражларын да төзеп куйган, чөнки ул чагындагы шәһәр төзелеше кодексы нормалары буенча бу рөхсәт ителгән. Болар нигездә капиталь булмаган корылмалар, ягъни чанадагы гаражлар. Әлбәттә инде, аларның җирләре дә, корылмалар үзләре дә теркәлмәгән, һәм хуҗалары алар буенча бернинди салым да түләми. Әмма бу эштә дә тәртип салу кирәк, һәм без шәһәр башкарма комитеты, торак-коммуналь ширкәтләре белән берлектә капиталь корылмаларны рәсмиләштерү һәм законсыз куелган вакытлыча гаражларны сүттерү буенча эшне башлап җибәрдек. Бүгенге көндә 17 шундый участок ачыкланды инде. Әлбәттә, бу эш җиңел генә бармый, гомер буена бер урында торган гаражын берәүнең дә сүттерәсе килми, әмма бу мәсьәләдә башка юл юк, һәм халык та моңа аңлап якын килер, дип ышанабыз.

Дача кишәрлекләре дә шәһәрнең эстетик йөзен бозу белән бер вакытта янгын һәм криминоген куркыныч учакларга әверелә бара. Дача участокларыннан кергән салымнарның елдан-ел кими баруын искә алып, алардан муниципалитетка да, халыкка да файда юк дәрәҗәсендә дип әйтергә була. Ташландык дача кишәрлекләрен бетереп, участокларны муниципаль ихтыяҗларга алу индивидуаль торак төзелеше өчен җир белән тәэмин итү проблемасын хәл итәргә булышыр иде. Хәзерге вакытта без участокларның хуҗалары базасын актуальләштерү эшен төгәлләп киләбез, киләсе адым дача участоклары хуҗаларының документлары белән эшләү булачак. Әлбәттә, бу эш тә четрекле, һәм шактый процедуралар үткәрү кирәк. Әмма районда һәм шәһәрдә җир мәсьәләләре контроль һәм тәртип булдыруны сорый. Һәм безнең палата бу яктан халыкка норматив база буенча консультацияләр бирергә һәм ярдәм итәргә әзер.

Лилия **МӨБАРӘКШИНА** сөйләште

ҖӘМГЫЯТЬ

## Игелеккә урын кайда да бар

**"АТП" командасы футболчылары Бикүле авылыннан балалар церебраль параличы белән чирләүче 10 яшьлек Эмиль Әхмәтовка ноутбук бүләк иттеләр.**

Игелек кылыр өчен ниндидер купшы чаралар, тантаналар оештырылуы да, кемнәрнеңдер чакыруы да мәҗбүри түгел, моның өчен бары күңел кушуы гына кирәк икән. Бикүледә яшәүче Лилия Әхмәтова һәм аның улы Эмиль шул көннәрдә моңа үзләре инандылар. Әнә, бернинди чакыруны да, сорауны да көтеп тормаганнар футболчы егетләр – җыелышканнар да заманча ноутбук күтәреп гөрләшеп килеп керделәр. Тиз генә тартмаларын таратып салып, Интернетка тоташтырдылар һәм кирәкле сайттан Эмильгә татар телендәге яраткан мультфильмнарын кабызып та бирделәр. Өйдә компьютерларының ватылуына күптән инде, шуңа да бала соңгы араларда яраткан мультфильмнарын да карый алмый торган, экранда таныш геройлары килеп чыккач исә шатлыктан йөзе балкыды, ә үзе әнисе генә аңлый торган телдә:

– Абыйлар яхшы, аларны ятарам, рәхмәт, - дияргә ашыкты.

Әхмәтовларга кунаклар бик сирәк килә. Ике яклы авыл йортында дүртәү яши гаилә. Лилиянең әти-әнисе, улы һәм үзе. Тормыш иптәше, инвалид бала йөген тартудан куркып булса кирәк, гаиләсен ташлап киткән, бүгенге көндә ни белән булса да ярдәм итүне кирәк дип тә тапмый. Әнисе дә – авыру, 1нче группа инвалид, үзенә дә карау кирәк. Өстәвенә, йортлары да авылның икенче башында, язгы-көзге пычракларда машиналар белән кереп йөрерлек түгел. Бу вакытта Эмильне хастаханәләргә йөртү турында уйларга да юк инде. Аннан, инвалид арбалары да бүлмәдә йөри торган гына, искереп тә бара. Дөрес, инвалид балаларга тиешле ярдәм чараларыннан файдаланалар үзе. Әмма әни дә, улы да җыела һәм машина багажнигына да сыя торган җиңел инвалид арбасы турында хыялланалар. Әмма аны алыр өчен дә шактый инстанцияләр үтәргә кирәк шул...

Шулай да Лилия һәм Эмиль Әхмәтовларның тагы бер зуррак хыялы да бар – уңайлыклы фатирда гомер кичерәселәре килә аларның. Шәһәр фатиры бер вакытта берничә проблемадан котылырга ярдәм итәр иде, югыйсә. Әмма, нишләптер, баланың яшәү шартларын өйрәнгән махсус комиссия шартлар да ярарлык, бер кешегә туры килә торган торак мәйдан да җитәрлек, дигән нәтиҗәгә килгән. Баксаң, Лилиянең әбисе үлгәч, әнисенә калган иске йортның мәйданы да исәпкә алынган икән. Монысына авыл халкы да, Лилия үзе дә аптырашта. Кысан йортта дүртәүләп яшәргә мәҗбүрләр ләбаса. Дөрес, район җитәкчелеге Әхмәтовларга ярдәм юлларын карый бүгенге көндә. Бусы өмет уята.

...Көтмәгәндә шулай бүләк белән килеп кергән егетләргә исә әни кеше үзе дә рәхмәт укып туя алмый.

– Балама үзем мондый бүләк ясый алмаган булыр идем, рәхмәт инде. Бер белмәгән егетләрнең шулай игелек эшләүләренә исем китте. Иң мөһиме – исән булсыннар, Ходай үзләрен юлларында саклап йөртсен иде, - дип изге теләкләрен җиткерә ул бүгенге көндә.

Ә "АТП" футбол командасы егетләре мондый рәхмәтләрне еш ишетә соңгы араларда. Чөнки инвалид балаларга, мохтаҗларга ярдәм итү биредә инде традициягә әверелеп бара. Шәфкать акцияләрен Җиңү бәйрәме уңаеннан Нурлатның картлар һәм инвалидлар йортыннан башлаган егетләр 1 июль – Халыкара балаларны яклау көненә ике гаиләгә 5әр мең сумлык ярдәм күрсәткәннәр иде, аннан соң, да һәр ай саен диярлек 1-2 гаиләгә ярдәм итәргә тырыша. Газета укучыларыбызда ярдәм итәр өчен акча каян алалар соң дигән урынлы сорау туар. Ярдәм күрсәтер өчен ниндидер зур иганәчеләре бардыр инде, диярсез. Юк икән шул, футболчы егетләр шәһәр һәм районның төрле оешма-предприятиеләрендә хезмәт куя, игелек өчен акчаларны да хезмәт хакларыннан арттыралар. Араларында студентлар да бар, алар да ярдәм юлларын таба. Тамчыдан күл җыела диюләре хактыр, күрәсең.

– Егетләрнең спорт белән шөгыльләнү белән бергә шундый игелекле эшкә дә вакыт табулары сөендерә генә, - ди команданың тренеры Марат Хәмидуллин. – Шул вакыт эчендә генә дә 9 гаиләгә ярдәм күрсәтергә өлгерделәр, димәк, шулкадәр гаиләгә шатлык бүләк иттеләр булып чыга. Егетләрнең бу башлангычын башка коллективлар, командалар да күтәреп алып, дәвам иттерсәләр тагы да яхшы булыр иде. Инвалид балаларны тәрбияләүче гаиләләргә кайчагында кечкенә генә ярдәм дә бик урынлы һәм кирәкле булып чыга бит. Аннан игелек кемдәдер кешеләргә ышаныч, яшәү дәрте дә уятырга сәләтле ул.

Ә егетләр өчен гаиләләргә барып, язмыш тарафыннан кыерсытылганнар белән очрашулар үзенә күрә бер тәрбия мәктәбе дә әле, ул аларны тормышны яратырга, язмыш турында уйланырга мәҗбүр итә. Әнә, бу көннәрдә Бикүледә яшәүче Эмиль һәм аның әнисе Лилиягә ничек тә булса ярдәм итәсе иде дип йөрүләре. Бу гаиләне бик тә бәхетле итеп күрәселәре килә аларның...

Лилия **МӨБАРӘКШИНА**

14 НОЯБРЬ – ХАЛЫКАРА ЛОГОПЕД КӨНЕ

# Сөйләшергә өйрәнәбез



Автор фотосы

**Иртәгә район мәгариф учреждениеләрендәге 8 логопеды-социаль һөнәр ияләре үзләренең һөнәри бәйрәмнәре – "Халыкара логопед көнен" билгеләп үтә.**

Алар арасында "Татарстан Республикасы ел тәрбиячесе – 2010" республика конкурсының "Укытучы – логопед" номинациясе җиңүчесе, район башлыгы гранты иясе, "Бала үсеше үзәге – балалар бакчасы"-ның югары категорияле укытучы-логопеды Наталья Дорожкина да бар. Аның бу өлкәдә эшләвенә 20 ел.

Укытучылар династиясеннән булган Наталья Викторовнага әлеге өлкә аеруча якын. Бабасы һәм әнисе фән укытучылары булсалар, Наталья мәктәпкәчә яшьтәге балалар белән эшләүне сайлый. Ел саен тәҗрибәле укытучы – логопед 25ләп балага сөйләмдәге кимчелекләрне төзәтергә булыша. Үз хезмәтенә иҗади якын килеп эшли ул.

- Сөйләм тайпылышын алдан диагностикалау - логопедик дәресләрнең уңышлы ышанычы, - ди укытучы - логопед. – "Бала үсеше үзәге – балалар бакчасы"нда балаларны тәрбияләү һәм өйрәтү бурычларының төп юнәлеше - сөйләм тайпылышын коррекцияләү һәм профилактикалау. Кызганычка каршы, балаларда сөйләм бозылышы елдан – ел ешрак очрый бара. Сөйләмне коррекцияләү – озын процесс, монда әти-әниләрнең сабырлыгыннан һәм баланың ярдәменнән башка мөмкин түгел. Логопедның эше өч буынны: балалар, әти – әниләр һәм педагогларны берләштерә.

Наталья Дорожкина логопедик ярдәмгә мохтаҗ балаларны ачыклап, өйрәнеп кенә калмый, алар белән даими шөгыльләнә, дәресләр үткәрә, заманча компьютер технологияләре белән интерактив уеннар үткәрә. Сөйләм үсеше буенча дәресләр бакчада яшь ярымнан башлана. Үз эшендә тәҗрибәле педагог иҗади алымнар, авторлык эшкәртмәләре һәм инновацион технологияләр куллана, яңа методик темалар өстендә эшли. Аның педагоглык концепциясе дә - һәр балага якын килеп һәм яңа программалар, технологияләр кулланып эшләү. Наталья Викторовна үз авторлык проектларын да булдырган. Төрле дәрәҗәге методик брошюралар аша ул үзе дә педагоглык тәҗрибәсе белән дә теләп уртаклаша. Ел саен һөнәри конкурсларда үзен сыный.

Логопед ул - медик, психолог һәм педагог та. Сөйләм патологиясе булган балаларны тәрбияләү үзенчәлекләрен һәм баланың сөйләме турында барысын да белгән белгечләр сабыйларны яратып эшлиләр. Кызганыч, соңгы елларда мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә әлеге белгечләргә ихтыяҗ арта, ә сөйләм бозылышы булган балалар арта бара.

- Сөйләмне коррекцияләп, алар балага аралашу байлыгы, җәмгыятьтә актив яшәү, мәктәптә уңышлы уку һәм нормаль үсеш мөмкинлеге бирәләр, - ди район мәгариф бүлеге җитәкчесе Линар Маняпов район логопедларын бәйрәм белән котлап.

**Зилия ӘКСАНОВА**

АВЫЛДАН-АВЫЛГА

## ЯШЬ ГАИЛӘЛӘР АВЫЛДА ТӨПЛӘНӘ

Зүзәйдә–Твороговлар, Сәләнгештә–Логиновлар быел яңа йортка күченделәр.

Яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү программасы буенча төзелгән йортларның хуҗалары – гомерләрен туган җирләре белән бәйләргә ниятләүчеләр. Алексей Творогов вахта белән читкә китеп эшләсә, хатыны Ольга авылда хат ташучы эшен башкара. Әлегә ул декрет ялында, гаиләгә икенче бала–малай алып кайтканнар. Ә Наталья Логинова исә "Нурлат сөте"ндә сыер савучы булып эшли.

## СӘЛӘНГЕШТӘ ОСТАЛАР КҮП

Авыл мәдәният йорты каршында берьюлы ике – "Осталар иле" һәм "Тылсымлы җөй" түгәрәге эшләве дә шул хакта сөйли. Аннан тыш, биредәге "Рябинушка" ансамбле дә соңгы елларда үз эшен активлаштырып җибәргән.

## ГӨМБӘЧЕЛӘРГӘ УҢЫШ МУЛ БУЛДЫ

Авылның иң оста гөмбәчеләре кем, дип сорасалар, сәләнгешлеләр һич тә икеләнмичә Александр Творогов белән Владимир Тюкаев исемнәрен атарлар. Беренчесе Зүзәйдән, икенчесе Сәләнгештән булган гөмбәчеләр янәшәдәге урманнардагы гөмбәле урыннарны биш бармакларыдай беләләр, ә хуҗабикәләр исә аларны ышанычлы итеп әзерлиләр. Казан һәм Нурлат ярминкәләрендә сәләнгешлеләр киштәсендә нәкъ менә алар тәкъдим иткән гөмбәләр була һәм бик тиз таралып та бетә.

**Сәкинә НУРУЛЛИНА**

ХӘТЕР-ХАТИРӘ

# "Җырларымда сезнең белән калам..."

**10 ноябрьдә нурлатлылар гаҗәеп һәм сәләтле кеше, ТРның атказанган мәдәният хезмәткәре Николай Глуховның истәлеген яд иттеләр. Бу көнне аңа 62 яшь тулган булыр иде.**

Мәдәният сараеның тулы тамашачылар залы. Күз явын алырлык софитлар. Николай Григорьевич үзе ничә тапкырлар чыккан сәхнә, хәзер инде биредә моңлы тавышлар үз чыгышларын аннан башка гына дәвам итә. Гомернең һәр көненә җитәрлек хатирәләр һәм, әлбәттә инде, талантлы якташыбыз бар тормышын багышлаган музыка. Боларның барысы да хәтер кичәсенә кабатланмас һәм үзгә халәт бирде. Ә экрандагы фоторәсемнән маэстро: "Мин җырларымда сезнең белән калам..", – дип пышылдый иде сыман.

Бу оештыручыларга "афәрин" дип әйтерлек матур кичә булды. Һәр сүз, һәр аккорд, һәр җыр күңелнең иң нечкә кылларына кагылды. Һәм бу искә алу кичәсенә килгән һәркемнең уртак фикере булды. ...Ул гаҗәеп кеше иде ...Ә нинди юмор көченә ия! Аның такмакларын хәтерлисезме?.. Теләсә нинди компаниянең үзәге... Николай Григорьевич Ходайдан бирелгән сәләткә ия иде... Һәрчак киңәшләре белән ярдәм итте... Укучыларын ничек ярата иде... Авыруын да онытып эшләде, беркайчан зарланмады... Болар аның дуслары, якыннары, коллегалары, укучылары тарафыннан яңгыраган сүзләрнең бик азы гына әле. Бу көнне Николай Глуховны искә алырга килүчеләрнең хәтерләрендә истәлекләр тагы никадәр булды. Күпләр аны үзләре өчен яңадан ачтылар, кайберләре сирәк очрашуларына һәм вакытны кире кайтарып булмавына үкенде. Маэстроның әнисе Раиса Семеновнаның күзләрендә ялтыраган күз яшьләрен дә оныта торган түгел. Улын югалтуга кайгырып елавы да иде бу ананың, аны истә тотуларына һәм яратуларына сөенүе дә.



Һәм менә сәхнә бушап калды. Софитлар сүнде. Концерт залы тып-тын булды. Ә маэстро хөрмәтенә яңгыраган алкышлар йөрәкләрдә дәвам итте. Һәм күпләр тормышыбызның һәр минуты күктән иңдерелгән байлык икәнлегенә инанды. Бәяләп бетергесез байлык. Һәм без аны рәхмәт белән кабул итә белергә тиешбез. Аның һәр минутын үзеңнән соң яхшы исем һәм якты истәлек калдырырлык итеп яши белү кирәк. Николай Григорьевич Глухов кебек. Кичәне оештырган Флюра Морзаханова боларны тамашачыларга гаҗәеп осталык белән җиткерә алды.

**Маргарита ЛИТТА**

# «ТВ-Үзгәртү» – беренче реалити-шоу!

**15 ноябрьдән "Нурлат" телерадиокомпаниясе инициативасы буенча Нурлатта реалити - шоу форматында беренче телепроект старт ала.**

Анда катнашырга 27 дәгъвачы теләк белдерде, жюри аерым критерийлар буенча 10 катнашучыны сайлап алачак. Проектның төп концепциясе–сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау, девизы – «Ябыгырга түгел, сәламәтлеккә беренче адым ясарга».

Проектны оештыручылар хатын-кызларга 3 ай дәвамында «Shifa» сәүдә үзәгендә «Infitno» фитнес-залында шөгыльләнеп, үз-үзләрен үзгәртергә мөмкинлек бирәләр.

Бернинди түләүсез! Бу чорда бер катнашучы белән фитнес-инструктор шәхси программа буенча, ә калганнары белән клуб тренерлары шөгыльләнәчәк. Катнашучыларны сайлап алу бу




якшәмбе көнне 14.00 сәгатьтә «Shifa» сәүдә үзәгендә узачак.

Проектны күзәтеп барыгыз! "Нурлат-ТВ" атнага 3 тапкыр күнегүләр язмасын Интернет челтәренә салачак, иң кызыклы моментларны атнага бер тапкыр "Нурлат-ТВ"ның аналитик программасында, ике атнага бер "Хәбәрләр" мәгълүматый программасында күрсәтәчәк.

Мәгълүматый партнерлар – "Дуслык"("Дружба","Туслах") газетасы, «DFM-Нурлат» һәм «Авторадио-Нурлат» радиолары.

РАЙОН ТОРМЫШЫННАН КҮПТӨРЛЕ ХӘБӘРЛӘРНЕ

**NURLAT-TAT.RU** САЙТЫНДА УКЫЙ АЛАСЫЗ

## КОТЛЫЙБЫЗ!

Бу көннәрдә иң кадерле кешебез - абыебыз **Гаяз Минһаҗетдин улы Таҗиевның** юбилее. Абый, без сине чын күңелдән олы бәйрәмең белән котлыйбыз! Тормышыңда зур уңышлар, исәнлек-саулык, гаилә бәхете, озын гомер телибез!

Күңел күгең һәрчак
аяз булсын,
Читләп үтсен
сагыш-борчулар.
Ныклы сәламәтлек
юлдаш булсын,
Аннан кадерлерәк нәрсә бар.
Туган көнең-юбилееӊ белән
Чын күңелдән
сине котлыйбыз.
Сәламәтлек, шатлык,
куанычлар
Күңел тынычлыгы телибез.

**Сеңлең Әлфия һәм Лилия, Айдар, Айзилә.**

**Киекледә** яшәүче Тәлгать һәм Сәрия Мөхәммәтовларның беренче мәхәббәт җимешләре булып дөньяга килгән кызлары **Рузалия Тәлгать кызының** 12 ноябрьдә гомер бәйрәме – 55 яшьлек юбилее иде. Аны чын күңелебездән шушы олуг бәйрәме белән тәбрик итәбез. Аңа исәнлекнең ныгын, гомернең озынын, шатлыкларның иң зурысын телибез.

Яшәгән саен яшәү
дәрте артсын,
Сәламәт булсын изге йөрәгең,
Улларың янәшәңдә булсын,
Озын булсын синең гомерең.
Кешелекле бит син,
олы җанлы,
Шәфкатьле син дуска, туганга,
Сәламәтлек
ташламасын сине,
Без бәхетле тик син булганга.
Ут уйнаткан уңган кулларың
Талчыгуны белмәсен,
Саулык, шатлык, куанычта,
Гөрләп үтсен алгы көннәрең.
Еллар үтә диеп борчылма син,
Еллар үтү берни түгел ул.
Сау-сәламәт булып
озак яшәү –
Үзе бәхет, үзе шатлык ул.

**Иң изге теләкләр белән әтиең, әниең, сеңелләрең исеменнән сине һәрвакыт яратучы һәм хөрмәт итүче сеңлең Гүзәлия.**

## НЕДВИЖИМОСТЬ

*2-комнатная квартира, ул. С.Разина, 4. Т. 8-927-243-65-08.
*2-комнатная квартира с индивидуальным отоплением, аэропорт. Т. 8-917-286-08-60.
*дачный участок, 9 соток, за 4-й школой. Т. 8-927-439-69-54.
*3-комнатная квартира с ремонтом, индивидуальное отопление, 2 этаж, ул. Нурлатская. Т. 8-927-037-48-98.
*дом. Т.: 2-19-57, 8-917-929-86-81.
*2-комнатная квартира, ул. Тельмана,6, 1 этаж, евроремонт. Т. 8-927-448-23-79.
*дом, «Афганский» мкр. Т. 8-927-047-40-55.
***1-комнатная квартира**, ул. Ленинградская, 17, 2 этаж, 560 000 руб; **2-комнатная,** ул. Циолковского, 7, 750 000 руб; **дом**, с. Бурьметьево, 130 000 руб. Т. 8-937-600-47-73. Алсу.
*2-комнатная квартира, г. Набережные Челны, мебель+ремонт, п. Зяб, 3 млн. руб. Т. 8-927-727-12-82. Ксения.
***1-комнатная квартира**, ул. Заводская, 560 тыс. руб., наличными; **2-комнатная,** ул. Заводская, 900 тыс. руб., ремонт; **2-комнатная**, ул. Шашина, 1100 тыс. руб.; **коммерческое помещение**, ул. Нурлатская, 1 млн. руб. Т. 8-929-727-12-82. Ксения.
*дом. Т. 2-04-04.
*2-комнатная квартира, центр. 8-927-450-16-85.
*3-комнатная квартира. Т. 8-937-629-32-87.
*2-этажный дом в пос. Единение (35 мельница). Вода, отопление, сан. узел в доме. Хоз. блок: гараж, баня, сарай. Срочно! Т. 8-937-778-12-22.
*2-этажный 5-комнатный жилой дом со всеми удобствами, частично с мебелью. Хоз. постройки: 3 гаража на 5 машин, двор благоустроен, 2 бани, 12 соток. Можно в ипотеку. Ул. Интернационалистов, 9. Срочно! Т. 8-937-778-12-22.

12+ **“ТНТ-Нурлат” тәкъдим итә**

**16 НОЯБРЬ**
Музыкаль тапшыру, чуваш телендә.
**18 НОЯБРЬ**
“Нурлат хәбәрләре”,
“Татнефть” хәбәрләре.
**20 НОЯБРЬ**
**“Нурлат хәбәрләре”.**
**“Сиңа диган җырым”**, музыкаль тапшыру
Программалар **19 сәгатьтә** башлана. **17, 19, 21нче ноябрьдә** иртәнге **7дә** кабатлап күрсәтелә.

**НАТЯЖНЫЕ ПОТОЛКИ ЛЮБОЙ СЛОЖНОСТИ.**
**Т. 8-9600-33-77-55.**

**Профнастил (9; С10; С20; С21; 7НС-44),оцинкованный, окрашенный**
- Сайдинг металлический, виниловый
- Доборные элементы
- Парогидроизоляция
- Водосточные системы
- Штакетник
- Профильные трубы

Кредит (предоставляют АО «ОТП Банк», АО «Альфа-Банк»).
*Доставка. Выезд на замер бесплатно.*
*г.Нурлат, универсальный рынок, магазин «Инструментград».*
*ТЕПЛИЦЫ*
**Тел.: 8-937-579-24-24, 8-987-409-27-06.**

## АВТОТРАНСПОРТ

*«ВАЗ-2112», 2006 г/в, гур, европанель. Т. 8-937-617-05-03.
*«Матиз», автомат, недорого. Т. 8-937-283-03-77.
*«Матиз», 2011 г/в., серебристо-белый, пробег 48 тыс. км., один хозяин, 170 тыс. руб. Т. 8-917-918-90-71.
*«КамАЗ-55111». Т. 8-937-594-02-94.
*«МТЗ-82». Т. 8-927-676-04-67.
*Мини-трактор. Т. 8-929-701-33-06.
*«ВАЗ-2107», 2002 г/в. Т. 8-927-476-92-40.

## ДРУГОЕ

*сахар-2250, мука-970, магазин «Юмарт» . Т. 8-927-445-68-55.
*бычки, телята разного возраста. Т. 8-927-483-06-10, 8-917-293-27-47.
*свадебное платье, шубка, туфли. Т. 8-937-297-87-91.
*жом. Т. 8-927-400-80-85.
*услуги погрузчика. Т. 8-927-672-31-49.

**ТЕПЛИЦА «НАДЕЖНАЯ»**
ОТ ЗАВОДА 3Х6-16000,
ГАРАНТИЯ 3 ГОДА.
**Т.: 8-927-040-97-37, 8-917-923-95-82, 8-929-722-29-89.**

*ПГС, песок, бут камень, жом. Т. 8-927-672-31-49.
*песок, ПГС, бут, цемент, керамзит, жом. Т.: 8-927-401-51-91, 2-03-43.
*телята, доставка. Т. 8-927-414-07-18.

**Стоматология**
**ООО «Мета-Дента»**
**- ТЕРАПИЯ** от 650 руб.
**- ОРТОПЕДИЯ-ПРОТЕЗИРОВАНИЕ**
**- УДАЛЕНИЕ.**
**Ул. К.Маркса, 2, тел.: 2-00-92, 8-927-489-99-96;**
**ул. Советская, 141**
(бывший клуб нефтяников),
**тел.: 2-23-00, 8-927-45-000-26.**
**Имеются противопоказания.**
**Необходима консультация специалиста.**

***18 ноября «Типография»***
***Нурлат***
***Только 1 день!!!***
***Ликвидация***
***Меховых Изделий 2014 г.!!!***
***Спешите!***
***Шубы, Дублёнки,Пуховики***
Пр-во:Россия
Действует кредит-0% первый взнос!*
*Подробности узнавайте у продавцов-консультантов или по т.8(3412)51-37-31*
*Организатор ИП Саралу О.И.*
***Ждём вас с 9.00 до 19.00***
*кредит предоставляется АО « ОТП Банк» № лицензии 2766 от 25 мая 2012г.
Реклама

*высокоудойная породистая корова (стельная). Т.: 9-01-48, 8-927-405-09-31.
*телята, сено, солома. Доставка бесплатно. Т.: 8-929-301-67-76, 8-937-309-03-57.
*поросята. Т. 8-937-770-46-59, 8-84344-4-98-72.
*жеребята, породистые лошади, п. Урняк. Т. 8-917-396-68-67.
*стол-тумба, палас, б/у. Т. 8-927-037-48-98.
*б/у зимняя резина на дисках R-13 «КАМА-ИРБИС». Т. 8-927-677-89-47.
*диван раскладной с ящиками, кресло, тумбочка под телевизор. Т. 8-927-670-35-89.
*коза. Т. 8-927-047-40-55.
*удобный современный диван в очень хорошем состоянии. Т. 8-927-404-81-54.
*телка, отел в январе. Т. 8-927-424-84-64.
*поросята, телки стельные, быки, свиньи на мясо. Т. 4-32-77.
*канарейки. Т. 8-927-672-06-04.
*холодильник б/у. Т. 8-927-466-10-32.
*коровы, или меняю на грузовую машину. Т. 8-927-748-89-15.
*овцы. Т. 8-927-487-12-09.
*угловой диван, два кресла, б/у, в хорошем состоянии. Т. 8-927-457-14-24.
*козочки. Т.: 8-927-463-87-00, 3-60-05.

## РАЗНОЕ

*ремонт холодильников на дому. Т. 8-927-419-56-48.
*ремонт компьютеров, установка программ. Т. 8-927-485-70-65.
*натяжные потолки. Т. 8-9270-365-365, Алексей.
*сантехника (отопление, водопровод, канализация). Т. 8-937-526-56-86.
*химчистка мягкой мебели и автомобилей, доступные цены. Т. 8-987-007-17-44.
*грузоперевозки, 4, 20 м., 16 куб., «Газель». Т. 8-927-247-12-61.
*доставка жома. Т. 8-987-294-31-04.
*помощь компьютеру. Т. 8-909-308-22-56.
*г/п. Т. 8-927-401-11-76.
*ремонт холодильников. Т. 8-927-247-93-50.
***доски - осина, сосна, брусья. Доставка. Т. 8-937-003-84-85.***
*копаем, чистим колодцы. Т. 8-937-294-65-52.
*копаем, чистим колодцы. Т. 8-937-776-79-45.
*отделочные работы. Т. 8-937-620-00-60.
***ремонт, настройка компьютеров, Wi-Fi, Интернета. Т. 8-937-005-14-51.***
*автоэлектрик. Т. 8-937-525-29-90.
*грузоперевозки. Т. 8-927-406-83-84.

## ТРЕБУЮТСЯ

*Вахта в г. Москву. Сборщики(-цы), грузчики, комплектовщики(-цы), упаковщики(-цы), фасовщики(-цы), кассиры. Т. 8-927-272-91-84.
*в НУАД ООО «Татнефтедор» токарь с опытом работы не менее 3-х лет. Т. 9-00-71.
*ООО «Вояджер – 2000» срочно водитель I-го класса, обращаться ул. Советская, 144, магазин ТД-2000.
*ООО «Сельхозснаб» менеджер по продаже. Т. 8-927-673-06-03.

## СДАЮТСЯ

*квартира посуточно. Т. 8-927-406-11-06.
*квартира, посуточно. Т.: 8-927-456-05-69, 8-986-712-11-79.
*в аренду помещение под парикмахерскую, под магазин в с. Ч. Вершины. Т. 8-927-263-16-17.
*в аренду в парикмахерской рабочие места. Т. 8-937-287-68-88.
*квартира, г. Казань, ул. Чистопольская, м. Козья Слобода. Т. 8-927-241-60-83.
*квартира семейным. Т. 8-937-594-03-02.
*в сервисном центре «Нурлат» на прокат прицепы, бетономешалки. Т. 8-927-426-24-78.
*квартира. Т. 8-927-463-74-88.




- ✓Оформление по ТК РФ
- ✓Иномарки, постоянное обновление
- ✓Высокий уровень зп
- ✓Корпоративная связь
- ✓Страховка
- ✓Ремонт в СЦ
- ✓При приеме обязательно наличие у водителя карты для тахографа ЕСТР

**ЗВОНИТЕ: +7-962-567-36-23**
**ТЕЛ. В НАБЕРЕЖНЫХ ЧЕЛНАХ: +7(8552)77-82-82**
*Делко. Реклама

## СНИМУ

*срочно 1-комнатную квартиру в центре на длительный срок. Чистоту и оплату гарантирую. Т. 8-927-425-56-52.
*квартиру на сахарном или в центре. Предоплата. Т. 8-919-686-26-85.
*квартиру, центр. Т. 8-927-240-58-38.
*квартиру, с/з. Т. 8-919-686-26-85.

## КУПЛЮ

*«ВАЗ», иномарки. Дорого. Т. 8-929-723-31-23.
*АВТО. ДОРОГО. Т. 8-937-588-36-46.
*пух гусиный, мокрый, сухой, старые подушки, перины. Т. 8-987-062-55-26.
*КРС и шкуры КРС, дорого. Т. 8-927-443-05-43.
*закупаем шкуры КРС по высоким ценам. Т. 8-927-045-44-86.
*кирпичный дом в черте города. Т. 8-927-695-33-66.
*«НИВУ» в любом состоянии. Т. 8-937-600-49-27.
*трубу металлическую, d-530 мм. Т. 8-937-042-11-51.

## ИЩУ РАБОТУ

*сторожа, охранника (магазин, офис), 4 разряд. Т. 8-906-114-16-00.
*охранника. Т. 8-987-068-41-66.
*домработник(-ца). Т. 8-917-932-75-06.
*сиделки, домработницы. Т. 8-927-421-18-10.

## ОБМЕН

*«Киа рио», 2014 г/в, автомат – на квартиру в г. Нурлат. Т. 8-929-793-93-24.

## ПОТЕРИ

*утерянный аттестат А №950463, выданный Нурлатской средней школой №2 в 1990 году на имя Александра Николаевича Абрамова, считать недействительным.

**Газетаның электрон версиясе nurlat-tat.ru да**

